| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **Нижнекамский городской<br>С О В Е Т** | **Түбән Кама шәһәр<br>С О В Е Т Ы** |
| 423570, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12<br>факс (8555) 43-15-35, 42-42-66 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр , 12<br>факс (8555) 43-15-35, 42-42-66 |


**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 20** **2015 елның 15 июне**

## Түбән Кама шәһәр Советының өченче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының өченче чакырылыш депутатларын сайлауны 2015 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Нижнекамская правда», «Туган Як» газеталарында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә http://www.e-nkama.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин